**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 14 августындагы 2877 номерлы карары**

**«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы»**
**шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф**
**учреждениеләре өчен конкурс уздыру тәртибе турындагы**
**нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары нигезендә, инклюзив белем бирүне үстерүдә һәм гамәлгә кертүдә мәгариф оешмаларының активлыгын арттыру, шулай ук инклюзив белем бирү өлкәсендә уңай педагогик тәҗрибәне киңәйтү максатыннан **карар бирәм**:

1. «Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. «Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс уздыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә субсидияләр бирү буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсен билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) «Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен җиңүчеләрне бүләкләү буенча тантаналы чараны оештыру буенча – 500 мең сум күләмендә, конкурсның кызыксындыру түләүләренә 4 000 мең сум күләмендә чыгымнарны 2026 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең

бюджет язмасындагы 0709 бүлек, 02 602 43600 «Мәгарифне, гомумшәһәр чараларын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар» максатчан статьясы чикләрендә тормышка ашырырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 августындагы
2877 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә инклюзив белем бирүне үстерүдә һәм гамәлгә кертүдә мәгариф оешмаларының активлыгын арттыруга, инклюзив белем бирү өлкәсендә уңай педагогик тәҗрибә таратуга юнәлдерелгән субсидия алуга Казан шәһәренең муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрү максатларын, бурычларын һәм тәртибен, шулай ук субсидия бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Әлеге нигезләмә өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- гомуми белем бирү учреждениесе – Казан шәһәре территориясендә урнашкан һәм Конкурста катнашучы булган муниципаль бюджет яисә автоном гомуми белем бирү учреждениесе;

- субсидия – «Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы белем бирү учреждениеләренә бирелә торган акча;

- Конкурста катнашучы – төп белем бирү программалары белән беррәттән, мәктәпкәчә, башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирүнең җайлаштырылган төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы, аерым белем алу ихтыяҗлары булган балаларны укытуда һәм үстерүдә инклюзив алымнарны үз тәҗрибәсендә кулланучы һәм алдагы ике елда Конкурста җиңүче һәм призер булмаган мәгариф учреждениеләре;

- гариза – әлеге нигезләмәнең 2.7, 2.8 пунктлары нигезендә катнашу өчен Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырыла торган документлар;

- Конкурс комиссиясе — Конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяли һәм Конкурста җиңүчеләрне һәм субсидияләр күләмен билгеләү функцияләрен

башкара торган коллегиаль орган.

1.3. Конкурсны уздыруның максаты – әлеге субсидия бирелә торган нәтиҗәләргә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, субсидия алучыны билгеләү.

1.4. Бурычлар:

- Казан шәһәре мәгариф оешмаларында инклюзив белем бирүнең гамәлдәге практикаларын туплау һәм анализлау;
- белем бирүдә инклюзив алымнарны үстерүгә җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чараларының игътибарын җәлеп итү.

1.5. Субсидия алучыларга субсидия бирүнең максатлары булып инклюзив белем бирүне үстерүдә һәм гамәлгә кертүдә мәгариф оешмаларының активлыгын арттыру, инклюзив белем бирү өлкәсендә уңай педагогик тәҗрибә тарату, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту шартларын булдыру өчен мәгариф оешмасын матди-техник яктан тәэмин итү һәм (яисә) мәгариф оешмасының педагогик хезмәткәрләрен инклюзив белем бирү юнәлешендә укыту яисә яңадан әзерләү хезмәтләре өчен түләү тора.

1.6. Субсидияне Конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста җиңүче дип танылган һәм вәкаләтле орган – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән субсидия бирү турында килешү төзегән Конкурста катнашучылар ала.

1.7. Субсидия максатчан билгеләнештә була һәм аны алучы тарафыннан әлеге нигезләмәдә каралмаган максатларга файдаланыла алмый.

1.8. Субсидия бирү 2026 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет язмасы чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.9. Субсидия бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба – Вәкаләтле орган) тора.

## II. Конкурсны уздыру тәртибе

2.1. Конкурсны уздыру турында белдерү Вәкаләтле органның рәсми порталында (https://obr.kzn.ru/) әлеге нигезләмәне раслаган көннән алып өч эш көне эчендә урнаштырыла. Белдерүдә түбәндәге мәҗбүри мәгълүматлар булырга тиеш:

- Конкурсны оештыручы атамасы, аның урнашу урыны адресы, почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры һәм Конкурсны оештыру өчен җаваплы затның урнашу урыны адресы;

- документлар тапшыру вакыты, урыны һәм тәртибе;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итә башлау һәм тәмамлау вакыты;

- нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр;

- Конкурс уздыру турында мәгълүмат урнаштырыла торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтның исеме;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару тәртибе, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару өчен нигезләрне, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларына үзгәрешләр кертү тәртибен билгели торган тәртип;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

- сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) субсидия бирү турындагы килешүне (алга таба – Килешү) имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган Конкурс нәтиҗәләрен урнаштыру көне.

Гаризаларны кабул итү Вәкаләтле органның рәсми порталында (https://obr.kzn.ru/) Конкурс уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.2. «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru/) сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында Вәкаләтле орган тарафыннан белдерүне, Конкурста катнашучыларның гаризалар тапшыру вакыты тәмамланганчы, бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырырга рөхсәт ителә.

Сайлап алу «Казан мәгариф порталы» рәсми сайтында (https://obr.kzn.ru/) аны гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

2.3. Конкурс ике номинация буенча уздырыла:

- «Иң яхшы инклюзив мәктәп»;
- «Иң яхшы инклюзив балалар бакчасы».

2.4. Конкурста катнашуга дәгъва кылучы учреждение субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- учреждениенең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү бурычы юк;

- учреждениенең Казан шәһәре бюджетына, үзгәртеп оештыру яисә ябу буенча чаралар үткәрүгә, авария (гадәттән тыш) хәлен булдырмауга, авария (гадәттән тыш) хәле килеп чыккан очракта, аның нәтиҗәләрен бетерүгә һәм торгызу эшләрен башкаруга субсидия бирү очракларыннан кала, субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үтәү вакыты чыккан бурычы юк;

- учреждениенең Казан шәһәре бюджетына законлы рәвештә гамәлгә кергән суд актлары, башкарма документлар, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, җирле администрациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очракларда бурычны каплауга бирелә торган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үтәү вакыты чыккан бурычы юк;

- учреждение алдагы ике елда Конкурс җиңүчесе һәм призеры түгел.

2.5. Сайлап алу ике этапта уздырыла.

Беренче (читтән торып уздырыла торган) этап – әлеге нигезләмә белән билгеләнгән конкурс материалларын бәяләү.

Икенче (урында уздырыла торган) этап – мәгариф оешмасына барып, критерийларны исәпкә алып, инклюзив белем бирү оешмасына мәгариф оешмасы тарафыннан булган тәҗрибәне тәкъдим итү, белем бирү оешмасы җитәкчесе (әлеге юнәлешне алып баручы җитәкче урынбасары) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инклюзив белем бирү өлкәсендә тәҗрибәне халык алдында күрсәтү.

2.6. Конкурсны уздыру вакыты.

Беренче (читтән торып уздырыла торган) этап – 2026 елның 31 августыннан 7 сентябренә кадәр.

Икенче (урында уздырыла торган) этап – 2026 елның 16 сентябреннән 23 сентябренә кадәр.

2.7. Конкурсның читтән торып уздырыла торган этабында катнашу өчен катнашучылар «“Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы” конкурсы» тамгасын куеп, kazanobr.info@yandex.ru электрон почтасына *.zip яки *.rar форматындагы архивлаштырылган бер файл белән түбәндәге материалларны җибәрә:

- әлеге нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча гариза;
- әлеге нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасындагы форма буенча Конкурста катнашучының портфолиосы;
- мәгариф оешмасының исемен, тулы адресын (юридик һәм фактик (әгәр юридик адресы башка булса), мәгариф оешмасы җитәкчесенең элемтә мәгълүматларын үз эченә алган *.pptx яки .pdf форматындагы электрон презентация (15 слайдтан да артык түгел). Презентациядә конвертерлар белән кысылмаган югары сыйфатлы фотосурәтләр; сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле укучыларга гамәлгә ашырыла торган инклюзив белем бирү моделен иллюстрацияләүче бер генә видео файдаланылырга мөмкин;
- гариза бирелгән айның беренче көненә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә;
- учреждениенең әлеге нигезләмәнең 2.4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар.

Конкурста катнашучы, Конкурс материалларын тапшырганда, Конкурста катнашучы турында мәгълүматны, Конкурста катнашучы бирә торган гариза турында, Конкурста катнашучы турында әлеге Конкурс белән бәйле башка мәгълүматны Интернет челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирә.

Конкурста катнашучы гаризада бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

2.8. Конкурста катнашучылар тапшырган документларга түбәндәге таләпләр куела:

- гомуми белем бирү оешмасының исеме, гомуми белем бирү оешмасының тулы адресы (юридик адресы башка булган очракта, юридик һәм факттагы адресы), гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе турындагы белешмәләр белән мәгълүмати заставканы үз эченә алган, *.pptx яки *.pdf форматындагы электрон презентация (15 слайдтан артык түгел). Презентациядә конвертерлар белән кысылмаган югары сыйфатлы фотосурәтләр; 60 секундка кадәр озынлыктагы бер генә видео файдаланылырга мөмкин.

- конкурс документларына кертелә торган документларның (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларның) мәгълүматны карауның һәркем өчен мөмкин булган программа тәэминаты чаралары белән бөтен документны карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматлардагы электрон күчермәләре, аларның эчтәлеге белән танышуны махсус программа яисә технологик чаралардан башка тормышка ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланмаган яисә якланмаган.

2.9. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар факт буенча алынган көнне теркәлә. Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң, Вәкаләтле органга кергән гариза теркәлми һәм Конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

2.10. Тапшырылган гаризалар Вәкаләтле орган тарафыннан, гаризалар тапшыру төгәлләнү көненнән санала торган җиде эш көне эчендә, әлеге нигезләмәнең 2.4, 2.7 пунктлары таләпләренә туры килүгә тикшерелә.

2.11. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда гаризаны кире кагу турында карар кабул итә:

- Конкурста катнашучының әлеге нигезләмәнең 2.4 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документларның документларга карата әлеге нигезләмәнең 2.7, 2.8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.12. Гаризада хәреф хатасы, басма хаталар, орфографик һәм арифметик хаталар булу Конкурста катнашуга рөхсәт итмәү өчен нигез була алмый.

2.13. Гаризалары тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килми дип танылган Конкурста катнашучыларга бу хакта тикшерү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан электрон почта аша хәбәр ителә.

2.14. Тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә дип танылган гаризалар тикшерү тәмамланган көннән алып бер эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан Конкурс комиссиясенә тапшырыла.

## III. Конкурс комиссиясе

3.1. Конкурс комиссиясенең шәхси составы Вәкаләтле орган әмере белән раслана һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең рәсми порталында (https://obr.kzn.ru/) урнаштырыла. Конкурс комиссиясенә мәҗбүри тәртиптә инклюзив белем бирү өлкәсе экспертлары кертелә.

Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән, жюри әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе составына кимендә биш кеше керә.

Конкурс комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның карарын раслый. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе Конкурс комиссиясе рәисе йөкләмәсе буенча Конкурс комиссиясе утырышын әзерләүне оештыру функцияләрен башкара.

3.2. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, Конкурс гаризалары карап тикшерелә башланганчы, бу хакта Конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы Конкурс комиссиясе эшендә катнашмый.

3.3. Конкурс комиссиясе:

- Конкурста катнашуга рөхсәт ителгән гаризаларны карап тикшерә;
- әлеге нигезләмәгә 3, 4, 5, 6 номерлы кушымталардагы бәяләү критерийлары нигезендә гаризаларны бәяли;
- Конкурста җиңүчеләрне билгели.

3.4. Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләр ачыкланганда баллар саны тигез булган очракта, Конкурс комиссиясе рәисе куйган бәяләр хәлиткеч дип санала.

3.5. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелергә тиеш түгел.

## IV. Гаризаларны бәяләү һәм Конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

4.1. Гаризаларны карап тикшерү Конкурс комиссиясе утырышында Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс

комиссиясе утырышы әлеге нигезләмәнең 2.6 пунктында билгеләнгән вакытларда урынга чыгып яки читтән торып уздырыла. Конкурс комиссиясе утырышы комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта тулы хокуклы булып санала.

4.2. Гаризаларны бәяләү Конкурс комиссиясе утырышында Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан әлеге нигезләмәгә 3, 4, 5, 6 номерлы кушымталардагы гаризаларны бәяләү критерийлары нигезендә баллар кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Һәр номинация буенча Конкурсның читтән торып уздырылган этабы нәтиҗәләре буенча гомуми рейтингта иң күп балл җыйган һәр номинация буенча алты катнашучы 2026 елның 9 сентябрендә игълан ителә.

4.4. Гаризаларны карап тикшерүнең читтән торып уздырыла торган этабы нәтиҗәләре бер эш көне дәвамында Конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аны утырышта катнашучы барлык комиссия әгъзалары имзалый.

Беркетмәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- гаризаларны карап тикшерү көне, вакыты һәм урыны;
- Конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү көне, вакыты һәм урыны;
- гаризалары карап тикшерелгән Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;
- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның Конкурс уздыру турындагы белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;
- Конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяләү эзлеклелеге, гаризаларны бәяләүнең каралган һәр критерие буенча гаризаларга бирелгән күрсәткечләр, гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән мондый гаризаларга тәртип номерлары бирү турында карар.

4.5. Конкурсның икенче (урында уздырыла торган) этабы кысаларында катнашучылар:

- белем бирү оешмасына барып, критерийларны исәпкә алып, инклюзив белем бирү өлкәсендә булган тәҗрибәсен белем бирү оешмасына тәкъдим итә (4, 5, 6 номерлы кушымталар);
- мәгариф оешмасының инклюзив белем бирү өлкәсендә эш тәҗрибәсен һәм иң яхшы практикаларын халык алдында күрсәтә.

4.6. Урында уздырыла торган этапта катнашу регламенты:

- эш тәҗрибәсен тәкъдим итеп, мәгариф оешмасы җитәкчесенең (әлеге юнәлешне алып баручы җитәкче урынбасарының) чыгышы – 15 минутка кадәр, жюри әгъзаларының сораулары һәм Конкурста катнашучының җаваплары – 5 минут;
- инклюзив дәрес/шөгыль яки дәрестән тыш шөгыль фрагменты – 20 минутка кадәр, жюри әгъзаларының сораулары һәм Конкурста катнашучының җаваплары – 5 минут;
- мәгариф оешмасында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләүче белгечләр (укытучы-логопед, укытучы-дефектолог, педагог-психолог) белән дәреснең бер өлеше – 20 минутка кадәр, жюри әгъзаларының сораулары һәм Конкурста катнашучының җаваплары – 5 минут.

4.7. Конкурс комиссиясе сәркатибе Конкурс комиссиясе утырышы узган көннән алып өч эш көне эчендә Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасы буенча катнашучылар рейтингын төзи.

4.8. Конкурс эшләрен ранжирлау нигезендә, җыелган балларны исәпкә алып, Конкурс комиссиясе Конкурсның урында уздырыла торган этабында һәр номинациядә I, II һәм III урыннарны алган җиңүчеләрне һәм призерларны һәм Гран-при ияләрен билгели.

4.9. Әлеге нигезләмә һәм критерийлар нигезендә Конкурста сайлап алуны уңышлы узган Конкурс катнашучыларына түбәндәге номинацияләр буенча субсидия бирелә:

4.9.1. «Иң яхшы инклюзив мәктәп»:

- гран-при – 600 000 (алты йөз мең сум);
- 1 нче урын – 400 000 (дүрт йөз мең сум);
- ике 2 нче урын – 300 000 (өч йөз мең сум);
- ике 3 нче урын – 200 000 (ике йөз мең сум);

4.9.2. «Иң яхшы инклюзив балалар бакчасы»:

- гран-при – 600 000 (алты йөз мең сум);
- 1 нче урын – 400 000 (дүрт йөз мең сум);
- ике 2 нче урын – 300 000 (өч йөз мең сум);
- ике 3 нче урын – 200 000 (ике йөз мең сум).

4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча бер эш көне эчендә беркетмә рәсмиләштерелә, ул Конкурс комиссиясе тарафыннан имзалана. Конкурста җиңүчеләр һәм субсидияләр күләме белән Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе сәркатип тарафыннан гаризалар рейтингы төзелгән көннән алып өч эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан Вәкаләтле органның рәсми порталында (https://obr.kzn.ru/) урнаштырыла.

Беркетмәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- урында уздырыла торган этапны уздыру көне, вакыты һәм урыны;

- Конкурста катнашучыларны бәяләү көне, вакыты һәм урыны;

- чыгышлары карап тикшерелгән Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;

- Конкурста катнашучыларның чыгышларын бәяләү эзлеклелеге, чыгышларны бәяләүнең каралган һәр критерие буенча гаризаларга бирелгән күрсәткечләр, чыгышларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән мондый чыгышларга тәртип номерлары бирү турында карар;

- килешүләр төзелә торган субсидия алучылар атамалары һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләме.

## V. Субсидияне бирү, алардан файдалануны контрольдә тоту, хисаплар бирү, субсидияне алучылар тарафыннан кире кайтару тәртибе һәм хисапка таләпләр

5.1. Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый торган жюри беркетмәсе Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2020 елның 29 декабрендәге 85 номерлы «Казан шәһәре бюджетыннан Казан шәһәренең муниципаль бюджет яисә автоном учреждениесенә башка максатларга субсидияләр бирү турындагы килешүнең үрнәк формасын раслау хакында»гы әмере белән расланган форма буенча Килешү төзү өчен нигез булып тора.

5.2. Килешү төзү өчен Конкурста җиңүче дип танылган учреждение, Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Вәкаләтле органның рәсми порталында (https://obr.kzn.ru/) урнаштырылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга электрон формада po.guo@mail.ru электрон почта адресына, максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге буенча тапшырылган документлар исемлеген теркәп, әлеге нигезләмәнең 7 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча гариза тапшыра. Документлар исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне, шул исәптән сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту шартларын булдыру өчен мәгариф оешмасын матди-техник яктан тәэмин итү һәм (яисә) мәгариф оешмасының педагогик хезмәткәрләрен инклюзив белем бирү юнәлеше буенча укыту яисә яңадан әзерләү хезмәтләре өчен түләү максатыннан тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә, милек (көчемсез милектән

кала) сатып алуга башлангыч сметаны кертеп, бюджет акчаларын әлеге тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән максатларга бирү кирәклеген нигезләүне, шулай ук тәэмин итүчеләрнең (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистик мәгълүматларны һәм (яисә) башка мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуы;

- субсидия бирү максаты ремонт (реставрация) ясау булган очракта, ремонт ясалырга тиешле объектлар исемлеге, мондый объектларны тикшерү акты һәм дефектлар исемлеге, чыгымнарның алдан эшләнгән сметасы;

- мәгариф оешмасының җиһазландыру максатыннан милек сатып алу гариза буенча субсидия бирү максаты булганда, сатып алырга планлаштырылган милек турында мәгълүмат;

- мәгариф оешмасы педагогларының инклюзив мәгариф юнәлеше буенча план буенча укыту яки яңадан әзерләү турында мәгълүмат.

5.3. Вәкаләтле орган:

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларның тулылыгын, алардагы мәгълүматның җитәрлек булуын һәм дөреслеген карап тикшерә;

в) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турында яки бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

Кирәкле барлык документлар тапшырылмаган яки алар тиешенчә тутырылмаган очракта, Вәкаләтле орган, карап тикшерү вакыты тәмамланырга кимендә ике эш көне кала, күрсәтелгән документларны ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен кире кайтара.

Хәбәрнамә учреждениегә Вәкаләтле органга электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә Вәкаләтле органга язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Учреждение тарафыннан җитешсезлекләрне бетерү вакыты – әлеге хәбәрнамә мәгариф учреждениесендә теркәлгәннән соң, биш эш көненнән артык түгел.

Учреждение тарафыннан документларның тулы җыелмасы тапшырылган һәм тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 1.5 пункты белән билгеләнгән максатларга туры килгән очракта, шулай ук максатчан субсидия бирүне кире кагу өчен әлеге Нигезләмәнең 5.4 пункты белән каралган нигезләр булмаса, Вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктында күрсәтелгән вакыт

эчендә субсидия бирү мөмкинлеге турындагы бәяләмә рәвешендә учреждениегә максатчан субсидия бирү турында карар кабул итә.

5.4. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

- учреждениенең тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләве;

- агымдагы финанс елында максатчан субсидияләр бирүгә структур бүлекчәнең бюджет язмасында каралган бюджет йөкләмәләре лимитларының тулысынча бүленүе.

Килешүгә кул куюдан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, учреждениегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүне кире кагу сәбәбен күрсәтеп, бу хакта хәбәрнамә җибәрелә.

Килешүгә кул куюдан баш тарту турында хәбәрнамә структур бүлекчәгә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә структур бүлекчәгә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә учреждениегә җибәрелә.

Кире кагу өчен нигез булып торган җитешсезлекләр бетерелгән очракта, учреждение документларны кабат җибәрергә хокуклы.

5.5. Конкурста җиңүче Вәкаләтле орган тарафыннан имзаланган килешүнең ике нөсхәсен алган көннән соң өч эш көне эчендә аларны имзалый һәм Килешүне имзалау турында Вәкаләтле органга электрон почта адресы буенча хәбәр итә.

Конкурста җиңүче килешүне имзалау турында хәбәрнамә җибәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә килешүнең имзаланган нөсхәсен Вәкаләтле органга шәхсән үзе тапшыра.

5.6. Килешү ике як тарафыннан да имзаланганнан соң төзелгән дип санала.

5.7. Субсидия алучы тарафыннан имзаланган Килешү әлеге нигезләмәнең 5.5 пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә тапшырылмаган очракта, субсидия алучы Килешү төзүдән баш тарткан дип санала һәм субсидия алу хокукыннан мәхрүм ителә.

5.8. Килешүдә субсидия бирүнең максатлары, субсидия бирүнең конкрет, үлчәп була торган нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең зурлыклары, тиешле программалар, проектлар нәтиҗәләренә ирешкәндә алу планлаштырыла торган матди һәм матди булмаган

объектлар һәм (яисә) хезмәтләр өлешендәге күрсәткечләрнең зурлыкларын да кертеп (мондый детальләштерү мөмкинлеге булганда), субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы, субсидия күләме, субсидия күчерү вакытлары (графигы), хисап бирү вакытлары, учреждение тарафыннан максатларны үтәмәгән очракта субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм вакытлары, Килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе, Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән гамәлгә куючы органга бюджет акчаларын алучы буларак субсидия бирүгә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта, гамәлгә куючы орган карары буенча Килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда өзү өчен нигезләр, шул исәптән учреждениене үзгәртеп оештыру (кушылу рәвешендәге үзгәртеп оештырудан тыш) яисә учреждениене бетерү, учреждение тарафыннан хокукый актта һәм (яисә) Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу белән бәйле нигезләр, учреждениенең Килешүне берьяклы тәртиптә өзүен тыю каралган.

Килешү проектын формалаштыру, максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда, Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.9. Килешүгә яклар тарафыннан үзгәрешләр кертелгән яисә өзелгән очракта, язма рәвештә өстәмә килешү төзелә.

5.10. Максатчан субсидия сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту өчен шартлар булдыруга мәгариф оешмасын матди-техник яктан тәэмин итү максатыннан товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә һәм (яисә) мәгариф оешмасының педагогик хезмәткәрләрен инклюзив белем бирү юнәлеше буенча укыту яисә яңадан әзерләү хезмәтләре өчен түләүгә бер мәртәбә бирелә.

5.11. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү аша сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту өчен шартлар булдыру һәм (яисә) укыту яки яңадан әзерләү аша мәгариф оешмасы педагогик хезмәткәрләренең инклюзив белем бирү юнәлеше буенча квалификациясен күтәрү тора.

5.12. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны укыту өчен шартлар булдыруга юнәлдерелгән кимендә бер товар, эш яисә хезмәт күрсәтүне документлар белән расланган сатып алу һәм (яисә) инклюзив белем бирү юнәлеше буенча кимендә бер педагогик хезмәткәрнең документлар белән расланган белем алуы яисә яңадан әзерлек узуы тора.

5.13. Вәкаләтле орган субсидия алучының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының территориаль бүлегендә ачылган исәп-хисап счетына килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидияне күчерә.

5.14. Субсидия алучы Вәкаләтле органга финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, хисап елынан соң килүче елның 10 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Килешүдә каралган форма буенча һәм вакытларда хисап тапшыра.

5.15. Вәкаләтле орган субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларга субсидия бирү нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткеченә ирешү өчен билгеләнгән барлык чор дәвамында, Килешүдә каралган хисапларга нигезләнеп һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2024 елның 27 апрелендәге 53н номерлы әмере белән расланган тәртипкә туры китереп, мониторинг уздыра.

5.16. Хисап бирелә торган финанс елында файдаланылмаган максатчан субсидияләрнең калган өлешләре Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

5.17. Хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Вәкаләтле орган Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә, Килешүдә билгеләнгән вакытларда кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле, максатчан субсидия акчаларының хисап елы булган финанс елында файдаланылмаган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле калган өлеше турында мәгълүмат җибәрә.

5.18. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында файдалану турындагы карар, Вәкаләтле орган белән килештереп, учреждение тарафыннан кабул ителә.

Максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган, учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итү өчен учреждениеләр Вәкаләтле органга учреждениенең учреждениеләр тарафыннан агымдагы финанс елының 1 гыйнварына элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турында мәгълүматны, шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын

һәм күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен), акча килеп ирешкәннән соң, өч эш көне эчендә тапшыра.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат килеп ирешкәннән соң, 10 эш көне эчендә килештерү/килештермәү турында карар кабул итә.

5.19. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешен тикшерә.

Муниципаль финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрәләр.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирү белән бәйле соралган документларны тапшырырга тиеш.

5.20. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәсә, шулай ук учреждение әлеге нигезләмәнең V бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаса, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

5.21. Максатчан субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару таләбе аны алган көннән башлап 30 календарь көн эчендә учреждение тарафыннан үтәлергә тиеш.

Субсидияне кире кайтару турындагы таләп билгеләнгән вакытта үтәлмәгән очракта, Вәкаләтле орган аны Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә.

5.22. Субсидия акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган өчен, шулай ук субсидия алу өчен тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә субсидия алучы учреждение җитәкчесенә йөкләнә.

---

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив
белем бирү оешмасы» шәһәр проектында
катнашучы муниципаль мәгариф
учреждениеләре өчен конкурс уздыру
тәртибе турындагы нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы»
шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф
учреждениеләре өчен конкурста катнашуга

______________________________________________

(белем бирү оешмасының исеме)

**ГАРИЗА**

| **Белем бирү оешмасының тулы исеме (кыскартуларсыз)** | **Белем бирү оешмасының почта адресы** | **Белем бирү оешмасы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә мәгълүматлары** |
|---|---|---|
| | | |

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫ**

________________________________________________
(белем бирү оешмасының исеме)

**ПОРТФОЛИОСЫ**

| **1. Гомуми белешмәләр** | |
|---|---|
| Адрес, телефон | |
| Белем бирү оешмасына нигез салу датасы | |
| Белем бирү оешмасының гамәлдәге рәсми сайты | |
| Белем бирү оешмасы контингенты [укучыларның гомуми саны күрсәтелә, шулардан сәламәтлегә ягыннан мөмкинлеге чикле укучылар саны, мигрант гаиләләрдән белем алучылар саны күрсәтелә. Мәсәлән, 1 000 укучы, шуларның 100 е – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле укучылар (10%)]. | |
| Соңгы ике уку елында өйдә белем алучы балалар саны (өйдә белем алучы балалар саны күрсәтелә, шулардан 2024-2025 уку елында, 2025-2026 уку елында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле балалар саны күрсәтелә). Өйдә укучыларның саны үзгәрү (үзгәрмәү) сәбәпләре күрсәтелә (100 сүздән артык түгел) | |
| Белем бирү процессын оештыру формалары | |
| 1. Мохитнең һәркем файдалана алырлык булуы [белем бирү оешмасының архитектура, пространство-вакыт, предмет-үстерү мохите турында мәгълүмат бирелә (200 сүздән артык түгел)] | |
| 2. Кирәкле җиһазлар сатып алу (нинди программалар кысаларында, сатып алу елын күрсәтергә) | |
| Белем бирү оешмасында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле балалар белән эшләүче педагогик хезмәткәрләр турында мәгълүматлар | |

| | |
|---|---|
| Белем бирү оешмасында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләүче укытучыларның (тәрбиячеләрнең), белгечләрнең гомуми саны, штат расписаниесе буенча ставкалар саны һәм фактта эшләүче белгечләр | |
| Соңгы 3 елда инклюзив белем бирү өлкәсендә квалификация күтәрү турында билгеләнгән үрнәктәге таныклыгы булган педагоглар саны | |
| 3. Психологик-педагогик ярдәм күрсәтү. Ярдәм хезмәте моделенең тасвирламасы (булган очракта). Мәгариф оешмасы сайтының тиешле битенә сылтама бирелә. Психологик-педагогик ярдәм күрсәтү формалары (200 сүздән артык түгел) | |
| 4. Психологик-педагогик консилиум (психологик-педагогик консилиум эше турында нигезләмә булу. Оешма сайтына сылтама, эш материаллары) | |
| 5. Белем бирү программасын гамәлгә ашыруның челтәр формалары (челтәр шартнамәләре төзелгән оешмалар исемлеге) булу, программалар исемлеге | |
| 6. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле балаларга белем бирүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән федераль, төбәк, муниципаль дәрәҗәдәге конкурсларда һәм программаларда катнашу | |
| **2. Белем бирү оешмасында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләрее чикле укучыларга инклюзив белем бирүнең гамәлдәге практикасы** | |
| 7. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле укучыларны укытуны регламентлаучы оешмаларның норматив-хокукый документлары һәм локаль актлары. Укыту һәм тәрбия программалары (белем бирү оешмасы сайтына сылтама) | |
| 8. Белем бирү оешмасы эшенең инклюзив системасы тасвирламасы (150 сүздән артык түгел) | |
| 9. Белем бирү оешмасының инклюзив практикасы тасвирламасы (150 сүздән артык түгел) | |
| 10. Инклюзив культура (инклюзив кыйммәтләр) булдыру өчен оештырылган чараларның тасвирламасы (250 сүздән артык түгел) | |

| | |
|---|---|
| 11. Инклюзив практиканы гамәлгә ашыру нәтиҗәләре (соңгы 2 елда. 200 сүздән артык түгел) | |
| 12. Укучыларның гаиләләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру, ата-аналар белән эш рәвешләренең төрлелеге | |
| 13. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле укучыларны өстәмә белем алуга кертү (сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өлеше, исемлек, өстәмә белем бирү программалары исемлеге) | |
| 14. Мәгариф оешмасында инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыруның перспективалы планы, төп юнәлешләре (150 сүздән артык түгел). Мәгариф оешмасында инклюзив белем бирүне үстерү буенча юл картасы (сылтама) | |

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив
белем бирү оешмасы» шәһәр проектында
катнашучы муниципаль мәгариф
учреждениеләре өчен конкурс уздыру
тәртибе турындагы нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы»
шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф
учреждениеләре өчен конкурсның читтән торып
уздырыла торган этабының конкурс материалларын
бәяләү кәгазе**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле белем алучылар өчен оешманың белем бирүдә архитектур мохите мөмкинлеген тәэмин итү. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикле, инвалид укучыларның белем алуын тәэмин итү өчен оешманы махсус укыту һәм тәрбия чаралары белән җиһазландыру (п.1, 2) | 10 |
| 2 | Психологик-педагогик ярдәмнең булуы, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен ярдәм хезмәте моделе турында мәгълүмат, логопедларның, дефектологларның, психологларның үзара хезмәттәшлеген оештыру, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны үстерүгә юнәлдерелгән уртак программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру (п.3, 4) | 10 |
| 3 | Белем бирү программасын гамәлгә ашыруның челтәр формалары, партнерлар, программалар исемлеге булу (п.5) | 10 |
| 4 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән федераль, төбәк, муниципаль дәрәҗәдәге конкурсларда һәм программаларда катнашу (п.6) | 10 |
| 5 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле укучыларга белем бирүне регламентлаучы оешмаларның норматив-хокукый документлары һәм локаль актлары, укыту һәм тәрбия программалары булу (п.7) | 10 |
| 6 | Мәгариф оешмасында эш һәм практиканың инклюзив системасы булу (п.8, 9, 10) | 10 |
| 7 | Инлюзив практиканы гамәлгә ашыру нәтиҗәләре (соңгы 2 елда) (11 п.) | 10 |

| №<br>т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 8 | Укучыларның гаиләләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру, ата-аналар белән эш формаларының төрлелеге (п.12) | 10 |
| 9 | Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның барысын да, шул исәптән сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле, инвалид укучыларны да җәлеп итүгә юнәлтелгән дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә белем бирү программалары булу. Мәгариф оешмасында өстәмә белем бирү белән тәэмин ителү проценты (п.13) | 10 |
| 10 | Мәгариф оешмасында инклюзив белем бирүне үстерүнең юл картасы булу һәм аның эчтәлеге (п.14) | 10 |
| 11 | Мәгариф оешмасында гамәлгә ашырыла торган инклюзив белем бирү моделен күрсәтә торган презентация тәкъдим итү | 10 |
| 12 | Мәгариф оешмасының эшчәнлек күрсәткечләренең презентациядәге портфолиога туры килүе (сыйфат һәм сан, сылтамаларның булуы) | 10 |
| **БАРЛЫГЫ** | | 120 |

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив
белем бирү оешмасы» шәһәр проектында
катнашучы муниципаль мәгариф
учреждениеләре өчен конкурс уздыру
тәртибе турындагы нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурсның урында уздырыла торган этабының конкурс материалларын бәяләү кәгазе**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Эш системасының актуальлеген нигезләү | 5 |
| 2 | Педагогик технологияләр һәм инструментлардан файдалану | 5 |
| 3 | Тәкъдим ителгән тәҗрибәнең социаль юнәлеше | 5 |
| 4 | Тәкъдим ителгән тәҗрибәнең системалы характеры | 5 |
| 5 | Презентациянең логикага нигезләнгәнлеге һәм эзлеклелеге | 5 |
| 6 | Коммуникацион эффектлар (җәлеп итү алымнары, сөйләмнең грамоталылыгы, нәфис сәнгать чараларын куллану һ.б.) | 5 |
| 7 | Тәкъдим итүнең үзенчәлекле булуы | 5 |
| 8 | Белем бирү характерында сайт, электрон массакүләм мәгълүмат чаралары битләрендә басылган материаллар булу, төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашу | 5 |
| 9 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле укучыларга өстәмә белем бирү өчен шартлар тудыру, түгәрәкләр булдыру | 5 |
| **БАРЛЫГЫ** | | 45 |

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә
5 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурсның урында уздырыла торган этабының бәяләү кәгазе [дәрес/дәрестән тыш шөгыль (белем бирү учреждениесе), шөгыль (мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе)]**

| № т/б | Бәяләү критерие | Балларның максималь саны |
|---|---|---|
| 1 | Дәреснең/шөгыльнең максат һәм бурычларын ачык һәм төгәл кую | 5 |
| 2 | Дәресне/шөгыльне оештыруда укучыларның катнашуы | 5 |
| 3 | Пространствоны һәм вакытны рациональ файдалану | 5 |
| 4 | Эчтәлекнең үстерү һәм тәрбияви йогынтысы | 5 |
| 5 | Эш алымнарының һәм ысулларының оригинальлеге | 5 |
| 6 | Педагогик культура: гомуми эрудиция, сөйләм һәм үз-үзеңне тоту культурасы, коллектив белән идарә итүдә такт | 5 |
| 7 | Дәрес вакытында психологик-педагогик аралашу стиленең нәтиҗәлелеге (гуманизм юнәлеше, иҗатташлык һәм хезмәттәшлек) | 5 |
| 8 | Укучылар эшчәнлеген активлаштыру алымнарына ия булу | 5 |
| 9 | Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен эшчәнлек төрләре сменасының оптимальлеге | 5 |
| **БАРЛЫГЫ** | | 45 |

«Казан шәһәренең иң яхшы
инклюзив белем бирү оешмасы»
шәһәр проектында катнашучы
муниципаль мәгариф
учреждениеләре өчен конкурс
уздыру тәртибе турындагы
нигезләмәгә
6 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурсның урында уздырыла торган этабының бәяләү кәгазе [мәгариф оешмасы белгечләре (укытучы-логопед, укытучы-дефектолог, педагог-психолог) белән дәресләр]**

| **№ т/б** | **Бәяләү критерие** | **Балларның максималь саны** |
|---|---|---|
| 1 | Шөгыльнең максат һәм бурычларын ачык һәм төгәл кую | 5 |
| 2 | Шөгыльне оештыруда укучыларның катнашуы | 5 |
| 3 | Эш алымнарының һәм ысулларының оригинальлеге | 5 |
| 4 | Коррекцион юнәлеше | 5 |
| 5 | Пространствоны һәм вакытны рациональ файдалану | 5 |
| 6 | Сөйләм культурасы | 5 |
| 7 | Һөнәри һәм шәхси сыйфатлар | 5 |
| **БАРЛЫГЫ** | | 35 |

«Казан шәһәренең иң яхшы инклюзив белем бирү оешмасы» шәһәр проектында катнашучы муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә 7 номерлы кушымта
(Форма)

**Муниципаль биремгә кертелмәгән бер тапкыр үткәрелә торган гомумшәһәр яисә башка чараларны оештыруга Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр алуга**
**ГАРИЗА**

Субсидия бирү максаты: ________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номеры | |
| 4 | Юридик адресы | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Әлеге гариза белән, субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык булуы турында хәбәр ителде<br>_______________<br>(имза) | |
| 11 | Учреждениенең нигезләмәнең 2.6 пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм документлар исемлеге буенча кирәкле документларны тапшырам | |

Директор ________________________________________________________________
(гариза бирүченең имзасы, вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү датасы: 20____елның «___»__________